**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН** | **ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** | **КАРАР**

2015 ел, 10 февраль | № 75

г. Казань

2015 елга мәдәният, сәнгать һәм кинематография өлкәсендә Татарстан Республикасы Президенты грантлары күләмнәре турында

Татарстан Республикасы Президентының «2015 елга мәдәният, сәнгать һәм кинематография өлкәсендә Татарстан Республикасы Президенты грантларын бирү турында» 2015 ел, 16 гыйнвар, ПУ-20 нче Указы нигезендә, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. 2015 елда мәдәният, сәнгать һәм кинематография өлкәсендә Татарстан Республикасы Президенты грантларының (алга таба – грантлар) түбәндәге күләмнәрен билгеләргә:

«Муса Җәлил исемендәге Татар дәүләт академия опера һәм балет театры» дәүләт бюджет учреждениесенә «Татар опера һәм балет театры дөньякүләм музыка киңлегенә интеграцияләнүенең яңа этабы: дөнья һәм милли музыкаль театр җәүһәрләрен популярлаштыру, матди-техник базаны модернизацияләү һәм ныгыту, халыкара фестивальләр, гастрольләр һәм проектлар үткәрү, театр спектакльләре иҗат итү һәм анда катнашу өчен сәхнә осталарын чакыру» проекты өчен – 155 800,0 мең сум;

«Галиәсгар Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры» дәүләт бюджет учреждениесенә «Иҗади проектларны тормышка ашыруда инновацион якын килү һәм ребрендинг, матди-техник базаны модернизацияләү һәм ныгыту, хәзерге заман татар драматургиясен популярлаштыру һәм Россиянең һәм ерак чит илләрнең әйдәп баручы театр коллективлары белән иҗади тәҗрибә уртаклашу» проекты өчен – 36 360,0 мең сум;

«В.И.Качалов исемендәге Казан академия рус Зур драма театры» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет мәдәният учреждениесенә «Дөнья әдәбияты әсәрләре буенча спектакльләр кую, театр сәнгатен пропагандалауга юнәлдерелгән иҗади проектларны тормышка ашыру, Россиянең һәм ерак чит илләрнең әйдәп баручы театр коллективлары белән тәҗрибә уртаклашу» проекты өчен – 6 360,0 мең сум;

«Татарстан Республикасы Дәүләт җыр һәм бию ансамбле» дәүләт бюджет мәдәният учреждениесенә «Осталыкны үстерү, матди-техник базаны

модернизацияләү һәм ныгыту, милли сәнгатьне саклау, үстерү һәм популярлаштыру» проекты өчен – 4 240,0 мең сум;

«Габдулла Тукай исемендәге Татар дәүләт филармониясе» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет мәдәният учреждениесенә «Музыка һәм нәфис сүз аша балалар һәм өлкәннәр аудиториясен җәлеп итүнең һәм тәрбияләүнең уңай дөньякүләм тәҗрибәсе буларак, концертларның филармония абонементлар системасын эшләү, үстерү һәм пропагандалау» проекты өчен – 8 798,0 мең сум, «Дөнья халыкларының музыка культуралары һәм традицияләре синтезы буларак джаз» проекты өчен – 8 400,0 мең сум, «Татар музыка фольклорын тикшерү, пропагандалау һәм, сәхнә аша күрсәтеп, Россия һәм дөнья халыклары музыка культурасына интеграцияләү» проекты өчен – 6 700,0 мең сум;

«Татарстан Республикасы Дәүләт симфоник оркестры» Татарстан Республикасы дәүләт автоном мәдәният учреждениесенә «Осталыкны арттыру һәм Россиянең һәм дөньяның атаклы башкаручыларын һәм дирижерларын җәлеп итү» проекты өчен – 12 720,0 мең сум;

«Татаркино» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет мәдәният учреждениесенә «XI Казан халыкара мөселман киносы фестивале» проекты өчен – 1 929,2 мең сум.

2. 2015 елда 241 307,2 мең сум күләмендәге грантларны түләү чыгымнары «2015 елга, 2016 һәм 2017 еллар план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында» 2014 ел, 27 ноябрь, ТРЗ-107 нче Татарстан Республикасы Законында «Татарстан Республикасының Мәдәният министрлыгы» ведомствосы буенча күрсәтелгән максатларга каралган акча исәбеннән тотыла дип билгеләргә.

3. Татарстан Республикасының Мәдәният министрлыгына:

бер ай эчендә грантларны алучыларның грантлар түләү өчен бүлеп бирелгән акчадан максатчан файдаланулары һәм иҗади эшчәнлекләренең нәтиҗәләре турында хисаплар кертү тәртибен һәм вакытларын билгеләргә;

2016 елның 1 мартына кадәр 2015 елда грантлардан максатчан файдалану турында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына хисап кертергә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры
вазыйфаларын башкаручы А.В.Песошин